Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Әлмәндәр авыл җирлеге Советының 2022 елның 5 июлендәге 72 номерлы «Керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру турында Әлмәндәр авыл җирлеге Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карары

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Әлмәндәр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Әлмәндәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 26 февралендәге 33 номерлы карары белән расланган Әлмәндәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында, шулай ук Әлмәндәр авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында Нигезләмәгә 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«в) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Әлмәндәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 16 августындагы 65 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының ” Әлмәндәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматны«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Апас муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару турында Тәртипкә 3 пунктның «г пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше), санлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы мәгълүматлар, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

3. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Әлмәндәр авыл җирлеге Советының 2021 елның 7 июнендәге 37 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының ” Әлмәндәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматны Апас муниципаль районы сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару турында Нигезләмәгә *2* пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше), санлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы мәгълүматлар, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми керемённән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Әлмәндәр авыл җирлеге Башлыгы.
Әлмәндәр авыл җирлеге Советы рәисе Р.Х.Җәләлиев